# КАРАР

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге составына керүче Оша пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 10 декабре №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 10 декабрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Ширәмәт авыл җирлеге Ошапункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, чакырылыш буенча хәрби хезмәт алып баручы солдатлар, контракт буенча, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, 500 сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертү белән килешәсезме:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 25 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 14 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 14 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге составына керүче Ошапунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Ширәмәт авыл җирлеге Оша пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, чакырылыш буенча хәрби хезмәт алып баручы солдатлар, контракт буенча, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә

мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, 500 сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Ширәмәт авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ширәмәт авыл җирлеге башлыгы В.И. Никишин